ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи, 422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

№ 4, 2020 елның 15 ноябре

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә 2020нче елның 15нче ноябрендә узган Октябрьский поселогында «2021 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Октябрьский поселогында чишмәне төзекләндерү, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 364 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 222 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 197 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 25 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогында гражданнар җыенын булып узды, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне

башкару буенча: - Октябрьский поселогында чишмәне төзекләндерү, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены карарын танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге башлыгына адресларга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш. Р. Азизов